ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЧКЕТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЧКЕТАҢ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.07.2023 Кичкетаң авылы № 12

«2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 28 пунктын гамәлгә ашыру максатларында Кичкетаң авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен уңай шартлар тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 24.07.2007 елның 209-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктына, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 21.01.2010 елның 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә,

1. «2023-2026 елларга Кичкетаң авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын расларга.
2. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының веб-адрес буенча портал составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка чыгарырга.
3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе И.Н. Җиһангәрәев

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитетының 28.07.2023 елның 12 номерлы карары белән расланды

# “2023-2026 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИЧКЕТАҢ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНДӘ КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШКУАРЛЫКНЫ ҮСТЕРҮ” МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

## Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның аталышы | «2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль максатчан программасы |
| Программаның хокукый нигезе | «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 24.07.2007 елның 209-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы |
| Программаның заказ бирүчесе | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программа чараларын үтәүчеләр | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитеты, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары (килешү буенча) |
| Программаның төп максатлары:<br><br>Программаның бурычлары: | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегендә эшкуарлык эшчәнлеге алып бару өчен уңай шартлар тудыру.<br><br>1. кече һәм урта эшкуарлык субъектларына (мөлкәти, консультация һәм оештыру) ярдәм күрсәтү;<br>2. кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын булдыру һәм аларның эшчәнлеген |

| | |
|---|---|
| | тəэмин итү;<br>3. Эшкуарлык эшчəнлеген пропагандалау;<br>4.кече һəм урта эшкуарлык субъектлары үсешенең микъдар һəм сыйфат күрсəткечлəрен саклап калу;<br>5. кече һəм урта эшкуарлык субъектлары продукциясен товар базарларына чыгару;<br>6. Иске Чекалда авыл җирлегендə халыкны эш белəн тəэмин итү һəм халыкның тормыш дəрəҗəсен арттыру; |
| Программаны гамəлгə ашыру сроклары | 2023-2026 еллар |
| Программа чаралары исемлеге | Программа чаралары исемлеге əлеге Программада китерелде |
| Программаны финанслау чыганаклары | - Җирлек бюджеты;<br>- бюджеттан тыш чыганаклар.<br>1) 2023 ел - 7 мең сум;<br>2) 2024 ел - 7 мең сум;<br>3) 2025 ел - 7 мең сум;<br>4) 2026 ел - 7 мең сум. |
| Программаны гамəлгə ашыруның көтелгəн нəтиҗəлəре | Кичкетаң авыл җирлеге территориясендə кече һəм урта эшкуарлык субъектларының тотрыклы үсеше;<br>Товар базарын конкуренциягə сəлəтле продукция һəм җирле житештерү хезмəтлəре белəн файдалану;<br>Социаль үсешнең өстенлекле юнəлешлəрендə эшчəнлек алып баручы кече һəм урта бизнес субъектлары вəкиллəрен арттыру;<br>Эш урыннары санын арттыру |

## Программаның тасвирламасы

## I. Гомуми нигезлəмəлəр

2023-2026 елларга «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегендə кече һəм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасы объекты (алга таба - Программа) Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегендə эшчəнлек алып баручы кече һəм урта эшкуарлык субъектлары җыелмасы булып тора.

Программаның предметы булып Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары, җәмәгать оешмалары, кече һәм урта бизнес субъектлары һәм халык арасында эшкуарлык эшчәнлегенә ярдәм итү һәм үстерү өлкәсендә барлыкка килә торган икътисадый, социаль һәм башка мөнәсәбәтләр комплексы тора.

Программаның гамәлдә булу даирәсе җирлекнең кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итүдән һәм үсештән гыйбарәт.

Программаның норматив базасы:

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль закон;

"Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 24.07.2007 елның 209-ФЗ номерлы Федераль закон;

"Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 21.01.2010 елның 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы

## II. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаның максаты - җирлекнең социаль-икътисадый бурычларын хәл итүгә ярдәм итүнең нәтиҗәле механизмнарын булдыру, кече һәм урта эшкуарлыкның өлешен арттыру нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру.

Куелган максатка ирешү өчен кайбер бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. кече һәм урта эшкуарлык субъектларына (мөлкәти, консультация һәм оештыру) ярдәм күрсәтү;

2. кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын булдыру һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү;

3. Эшкуарлык эшчәнлеген пропагандалау;

4. кече һәм урта эшкуарлык субъектлары үсешенең микъдар һәм сыйфат күрсәткечләрен саклап калу;

5. кече һәм урта эшкуарлык субъектлары продукциясен товар базарларына чыгару;

6. Кичкетаң авыл җирлегендә халыкны эш белән тәэмин итү һәм халыкның тормыш дәрәҗәсен арттыру;

Программаны гамәлгә ашыру срогы - 2023-2026 еллар.

## III. Программаның техник-икътисадый нигезләмәсе

Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү - җирлекнең социаль-икътисадый үсешендә даими өстенлекле юнәлешләрнең берсе. Икътисадый актив халыкны эшкуарлык эшчәнлегенә җәлеп итү иҗтимагый муллык үсешенә, җәмгыятьтә социаль-сәяси тотрыклылыкны тәэмин итүгә, халыкның мәшгульлегенә булышлык итүгә, төрле дәрәҗәдәге бюджетларга керемнәр артуга ярдәм итә. Икътисадның тиз һәм тотрыклы үсешен алдынгы мәгълүмати-коммуникация

һәм идарә технологияләрен кулланучы конкурентлыкка сәләтле кече һәм урта бизнес тәэмин итәргә сәләтле. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү системалы алымнар һәм нигезләнгән финанс кертемнәре таләп итә.

## IV. Программа чаралары исемлеге

Әлеге Программаны гамәлгә ашыру механизмнары аша югарыда куелган бурычларны хәл итүне тәэмин итәргә тиешле программа чаралары исемлеге Программага кушымтада бирелгән.

## V. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау чыганаклары авыл җирлеге бюджеты акчаларын һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчаларын үз эченә ала. Финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм ел саен корректировка булырга тиеш.

## VI. Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган социаль-икътисадый файда

Программа максатларына ирешү һәм бурычларын хәл итү түбәндәге нәтиҗәләрне алырга мөмкинлек бирәчәк:

- кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү инфраструктурасын үстерү;
- кече һәм урта эшкуарлык субъектлары санын арттыру;
- өстәмә эш урыннары булдыру һәм кече һәм урта бизнеста эшләүчеләр саны арту, халыкның нәтиҗәле мәшгульлеген тәэмин итү, вакытлыча буш һәм өлешчә мәшгуль халыкны хезмәт эшчәнлегенә җәлеп итү;
- кече һәм урта эшкуарлык субъектлары чыгара торган продукциянең күләмен һәм төрлелеген арттыру, аның сыйфатын күтәрү һәм чыгымнарны киметү, киләчәктә бәяләрне тотрыклы тотрыкландыру;
- конкуренцияне үстерү;
- инновацион өлкәдә эшләүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү;
- кече һәм урта эшкуарлыкта эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакы дәрәҗәсен арттыру;
- кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүне тоткарлый торган административ киртәләрне һәм каршылыкларны юкка чыгаруга ярдәм итүгә юнәлдерелгән механизмнарны үстерү.

## VII. Программаны гамәлгә ашыру белән идарә итүне оештыру һәм аны үтәү барышын күзәтү

Программа чараларының үтәлешен тикшереп тору Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе йөзендә Кичкетаң авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитеты Программа чараларын үтәүнең барышы турында Кичкетаң авыл җирлеге советына ел саен хисап елыннан килүче елның 1 февраленә хәбәр итә.

## VIII. Программа чаралары исемлеге

| Т/с | Чараның аталышы | Үтәү срогы (еллар) | Башкаручы | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитетына кергән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгатьләре белән эшне оештыру һәм үткәрү | 2023-2026 | Кичкетаң авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе | - |
| 2 | Кичкетаң авыл җирлегенең кече һәм урта эшкуарлык мәсьәләләре буенча норматив актлар проектларын эшләү | 2023-2026 | Кичкетаң авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе | - |
| 3 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын эшкуарлык үсешенә ярдәм итү һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат белән тәэмин итү, семинарлар уздыру | 2023-2026 | Кичкетаң авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе | Ел саен 2 мең сум (җирлек бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар) |
| 4 | Кичкетаң авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мониторинг | 2023-2026 | Кичкетаң авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе | Агымдагы финанслау кысаларында |
| 5 | Кече һәм урта бизнес субъектлары җитештергән продукцияне презентацияләүне оештыру һәм үткәрү | 2023-2026 | Кичкетаң авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе | Агымдагы финанслау кысаларында |
| 6 | Халыкның якланмаган катламнарына, бизнес алып баруның перспективалы | 2023-2026 | Кичкетаң авыл җирлеге Башкарма комитеты | Агымдагы финанслау кысаларында |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | булуы турында эшсезләргә мәгълүмат бирү буенча эшләр башкару | | җитәкчесе | |
| 7 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе территориясендә үткәрелә торган күргәзмәләрдә, ярминкәләрдә, конкурсларда катнашуга җәлеп итү | 2023-2026 | Кичкетаң авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе | Ел саен 5 мең сум (җирлек бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар) |
| 8 | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген (җир кишәрлекләреннән тыш) ташламалы шартларда кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә арендага бирү | 2023-2026 | Кичкетаң авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе | Агымдагы финанслау кысаларында |